Фәтхи Бурнаш

(1898—1946)

Фәтхелислам Закир улы Бурнашев 1898 елның 13 нче январенда Чувашстанның Батыр районы Бикшик авылында туа. Әтисе, кайчандыр мәдрәсә тәмамлаган шактый белемле кеше, авылда байтак вакыт мулла булып тора. Аң-белемнең кирәклеген яхшы аңлаган Закир абый унбер баладан икесен —Фәтхине һәм Вафаны Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга бирә.

Мәдрәсәнең югары сыйныфларында укыганда Фәтхи Бурнаш әдәбият, әдәби иҗат белән якыннан кызыксына башлый. Шактый бай тормыш тәҗрибәсе булу, көнчыгыш һәм рус әдәбиятын яхшы белү, әдәби процесстагы күтәренкелек аны актив иҗатка этәрә. Яшь автор «Язмыш», «Сукбай», «Саташкан кыз» кебек драма әсәрләрен яза, шигырь-поэмалары басылып чыга. Фәтхи Бурнашның башлангыч иҗат тәҗрибәләре беренче бөтендөнья сугышы чорына туры килә һәм, билгеле инде, әлеге тарихи вакыйгага автор мөнәсәбәте дә аларда чагылыш таба. Әдип үзәккә кеше язмышы мәсьәләсен куя һәм чын бәхеткә ирешү өчен җәмгыятьтәге гаделсезлекләрне бетерергә, хатын-кызның ирләр белән тигезлегенә, һәркемнең мәгърифәтле булуына, халкы өчен хезмәт итәргә әзер торуына ирешергә кирәк дигән фикерне үткәрә.

«Яшь йөрәкләр» драмасы сурәтләнгән вакыйгалары, күтәрелгән мәсьәләләре белән М. Фәйзинең «Галиябану»ына күпмедер аваздаш. Ләкин Ф. Бурнаш үзенчәлекле хәрәкәт үстереләше һәм конфликтның чишелешен тапкан. Әсәр тарихи чор картиналарын, сугыш һәм революцияләр чоры татар авылы тормышын сурәтләве, төрле гореф-гадәтләрнең, йолаларның киң планда бирелүе белән әһәмиятле.

1920 елны Ф. Бурнашны «Кызыл Армия» газетасының мөхәррире итеп билгелиләр. Ул чыгудан туктагач, «Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының баш мөхәррире итеп күчерелә. Әдип шулай ук Казанда чыга башлаган «Чаян», «Безнең юл» журналларын оештыруда да зур активлык күрсәтә.

20 — 30 нчы елларда Ф. Бурнаш күпсанлы публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләрендә үзен тирән белемле, укымышлы яңалыклар белән даими танышып баручы, принципиаль, намуслы журналист һәм тәнкыйтьче итеп таныта.

Драматургия һәм театр сәнгате аерылгысыз булган хәлдә, Ф. Бурнаш аларның үсешенә әсәрләре белән дә, оештыручы буларак та 1926 елларда Татар дәүләт академия театрының директоры булып эшли), мәкалә-рецензияләре аша да җитди өлеш кертә.

Ф. Бурнашның 20—30 нчы елларда язган «Адашкан кыз», «Камали карт», «Илһам», «Олы юл белән», «Хат» һ. б. драма әсәрләре чорның тормыш картиналарын реалистик буяуларда сурәтләве белән әһәмиятле. Алардагы төп мотив — яңа җәмгыятьнең бүгенгесенә һәм киләчәгенә дан җырлау. Драматург алгы планга яңа тормыш өчен армый-талмый көрәшүче уңай геройларны чыгара. Кызыклы сюжетлары, көтелмәгән каршылыкинтригалары, персонажларның характер буларак ачылулары һәм әдипнең үзенчәлекле, сурәтләүләргә бай бизәкле теле белән әлеге әсәрләр бүген дә укучыларның игътибарын җәлеп итә.

Фәтхи Бурнаш тәрҗемәче буларак та уңышлы эшли. Ул рус әдәбияты классикаларыннан А. Пушкин, Л. Толстой, И. Тургенев, М. Горький, А. Толстой, Н. Островский һ. б. әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

1931—1935 елларда Ф. Бурнаш Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшли. Ә инде 1936 елдан башлап үзенең бөтен көчен, талантын татар опера сәнгатен оештыру, аның репертуарын баету һәм яхшырту эшенә бирә.

Ф. Бурнашның бай иҗатына караш, мөнәсәбәт шактый каршылыклы була. 20 нче еллар ахырында матбугатта кискен тәнкыйть мәкаләләре күренә. «Таһир-Зөһрә» трагедиясенә «сарайлар, ханнар, князьләр, мәчетләр» турында дигән ярлык тагылса, ә соңрак, гомумән, реакцион характердагы әсәр дип билгеләнә. 30 нчы еллар уртасында «шәхес культы»ның кара болытлары Ф. Бурнашның баш өстендә торган саен куера бара. 1940 елның 24 нче августында ул кулга алына. Тормыш юлындагы кайбер фактларга, әсәрләренә кимчелекләргә нигеалә-неп, аннан «халык дошманы» ясыйлар һәм 10 елга лагерьга җибәрергә хөкем итәләр. Таныльган әдипнең гомере 1942 елның 1 нче августында лагерьда өзелә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ф. Бурнашның тормыш юлын сөйләгез.
2. Ф. Бурнаш беренче әсәрләрендә нинди темаларга мөрәҗәгать итә?
3. Әдип драматургия һәм театр сәнгатен үстерүгә нинди өлеш кертә?

ТАһИР-ЗӨһРӘ

КАТНАШАЛАР:

Хан
Ханча
Зөһрә — аларның кызы.
Вәзир
Таһир — вәзирнең улы.
Гарәп — сарай хадиме.

Гаскәр башлыгы
Акбикә
Алка } гөл патшасы кызлары.
Айсылу
Кияү — Шаһзадә.
Җәллад

Җырчылар, уенчылар, биючеләр, җарияләр, гаскәрләр, сарай хадимнәре һәм башкалар.

Беренче пәрдә

Сарай бакчасы. (...) Вакыт төн, ай яктысы якты. Баскычтан Зөһрә төшә. Ак киемнән. Башында такыя. Өстеннән пәрдә салган. Аягына башмак кигән. Чәче тузып иңбашларына төшкән. Киемнәре кыйммәтле ташлар белән бизәлгән.

Зөһрә. (...) Әле ул юк. Тукта... Килерме соң?..
Килер, килер, минем чибәрем.
Килмәс булса, тагын елый-елый
Чакырып хатлар язып җибәрем.
Аппак кынам, иркәм, кил диярмен,
Бир, диярмен, миңа кулыңны;
Синсез миңа дөнья хәсрәт йорты,
Синсез болыт каплый юлымны
Мәхәббәт! Син нинди көчле... Кайчан
Безне янган утка саласың.
Кайвакытта шатлык дәрьясында
Йөздертәсең ата баласын.

Сулдан Таһир чыга да туктый. Ул чуар итектән. Чиккән кызыл күлмәк өстеннән укалы камаул кигән, чәчләре озын. Киң чалбары кайтарылып итекка төшкән, башында энҗеле такыя. Билендә кылыч, ханҗәр.

Таһир. Хәерле кич иркәләсен гүзәлләрнең гүзәлен!
Зөһрә. Айга карап бик күп ялгызсыну
Ялыктыргач сине чакырттым.
Утыр бире, Таһир, ятсынма син,
Чит күрмә син мине, акыллым!
Таһир. Нигә кирәк алар? Мин бик шатмын!
Зөһрә. (...) Әйт, канатым, Таһир, ниләр кылыйм,
Күкрәгеңә ничек юл салыйм?
Таш күңлеңә ничек мәхәббәттән
Тик бер кисәк кискен ут салыйм? (...)
Үпкәндә дә син бит сизмәдең...
Кичер, аппак кынам, сүзләремне,
Янды йөрәк, артык түзмәдем. (...)
Таһир. Сөям, Зөһрәм, өзелеп сөям. Бары
Сине генә шашып сөям мин.
Сәждә кылам ятып аллыңа...
Мәҗнүн[1] колың инде күптән мин.
Янсын инде йөрәк ялкынында...
Асыл ярым, кичер егетне!
Таңгы төшләр кебек, оныт мине,
Яндырдым мин күптән өметне...
Мин ялгызым түзем сугышчы,
Атам минем түбән чыгышлы.
Ханым бирмәс миңа кулыңны,
Мин табармын ялгыз юлымны...
Зөһрә. Кире кайтар, бәгърем, сүзләреңне!
Яндырма син мине утында;
Ничкем били алмас йөрәгемне —
Ихтыярым синең кулыңда...
Кирәк түгел... атам сарайларын,
Хакимлеген ятка калдырсын,
Теләмимен ничнәрсәсен аның,
Тәхетләрен зарым яндырсын!
Әгәр монда безгә көн булмаса,
Туган илнең чиген үтәрбез,
Һәммә җирдә кызарып кояш бата —
Торган илне туган итәрбез.
Таһир. А, гөлкәем, рәхмәт — бу көчләрне
Көтми идем сиңнән әлегәчә.
Бәгърем, тик син миңа яр булырсың,
Аерылмабыз, дустым, гүргәчә! *(Үбә.)*

Гарәп керә.

[1] Мәҗнүн — юләр.

Гарәп. Сәлам булсын гүзәл хан кызына!
Сәлам булсын батыр Таһирга!
Зөһрә. Сәлам булсын!
Сезгә йомышым юк минем хәзергә. (...)
Таһир. Хәерле таң сиңа, кардәшем...
Уңыш бирсен авыр хезмәтең! *(Китәләр.)*
Гарәп *(уртага чыга, ачу белән).*
Дөнья җәннәтендә ник аңарга
Чәчәкләрдән тәхет корылган;
Нинди авыр миңа!.. Шулай ук соң
Очар микән бәхетем кулымнан?..
Шуның кулларында Зөһрә матур
Кысылганда ничек чыдадым?
Кара күзләреннән үпкән чакта,
Ничек чыгып башын чапмадым. (...)
Я мин, я син! Минем алмаз хәнҗәр
(ачу белән хәнҗәрен уйната.)
Бик күп Таһир башын өзгән ул.
(Тиз генә югала.)

Пәрдә төшә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Зөһрәнең Таһирга мәхәббәт хаты язуын сез ничек аңлатыр идегез? Автор моның белән нәрсә әйтергә тели?
2. Мәхәббәтне Зөһрә нәрсәгә тиңли? Шул юлларны укып күрсәтегез.
3. Ни өчен Таһир башта Зөһрәнең яратуын кире кага?
4. Гарәпнең сүзләре нинди уй-фикерләр тудыра?

Өченче пәрдә

Сарай эче. Арткы планда колоннада. Артта су, ерактә шәһәр. (...) Сакчылар, сарай гаскәрләре керә. Диван әгъзалары, аннан вәзир, ханча, хан керәләр.

Хан. Балалардан нинди хәбәрләр бар?
Далалардан килгән кемнәр бар?
Сугыш сафларында туган илгә
Шатланырлык нинди хәлләр бар? (...)
Гаскәр башлыгы.
Сугыш беткән, дошман җиңелгән,
Данлык белән гаскәр күмелгән,
Батырларны кабул итәргә
Рөхсәт сорыйм, ханым, мин сездән. (...)

(...) Гаскәрләре белән уралып Таһир керә.

Таһир. Сугыш бетте, дошман җиңелде,
Укчыларым сафка тезелде,
Туган илгә шатлык, мәхәббәт,
Кайнар сәлам алар китерде.
Хан. Таһир!
Халык. Батыр Таһир!
Ханча. Нәләтләнгән Таһир!
Гарәп. Таһир!
Тагы яраланды күкрәгем...
Вәзир. Газиз балам минем, йөрәгем...
Хан. Таһир, саклан каргышларымнан! (...)
Качкан өчен минем зинданымнан
Җәза кылырмын мин таныннан! (...)
Гаскәр башлыгы.
(...) Озак еллар сугыш илебезнең
Тамырларда канын киптерде,
Һәркөн безгә авыр җиңелүләр,
Һәлакәтләр генә китерде.
Шул вакытта гаскәр аңа килде,
Тар зинданнан аны чыгарды.
Авырлыкның ачы көннәрендә
Таһир килде сугыш сафына.
Килде мәхәббәттән юллар урап.
Үз халкына биргән антына.
Хан. Ничек? Таһир?
Ялгышасың түгелме?
Гаскәр башлыгы.
Түгел, ханым!
Аңа шунда байрак бирелде.
Җир тетрәде Таһир кылычыннан,
Сугыш бетте — дошман җиңелде. (...)
Хан. Сиңа, Таһир, минем шартым бар;
Үтәр булсаң, кичәм; үтәмәсәң —
Кичермәскә сине антым бар.
Кил мондарак! Хәзер үз каршымда
Шигырь сөйлә халык алдында;
Ләкин аң бул, шигырең юлларында
Минем Зөһрәм исемен сагынма;
Әгәр шул шартымны үтәр булсаң,
Мәңге сине азат итәрмен;
Әгәр аннан күңелең алалмасаң,
Кыганмыйча һәлак итәрмен!

Гарәп думбра китерә. Паузадан соң Таһир бер моңлы көй уйный.

Таһир *(җырлый).*

Мин тудым, көннең ләкин якты кояшын күрмәдем;.
Яшьлегем үтте ятим, әнкәм кочагын белмәдем,
Мин канымның эссесен бирдем туган халкым өчен;
Мин җанымны бүлдем урталай ярым-яртым өчен.
(Зөһрә чыга.)
Тик күңелне кол итә алмаслар аңардан башкалар.
Кул сузалмаслар, йөрәктә мәңгегә саклар күңел,
Ташламам мин Зөһрә исемен, мәңгегә ятлар күңел.

Сазы кулыннан төшә. (...)

Хан *(паузадан соң).*

Үзе яшы Таһир язмышын!
Үзе каршылады каргышын!
Ләкин мәрхәмәтем киң минем.
Таһирны мин тагын кичердем. (...)
Бер сандыкка хәзер аны салсыннар!
Өстен аның ныклап капласыннар.
Тәкъдир язмышына ташшырсыннар —
Бер ялгызын суга ташласыннар! (...)

Таһирны сандыкка салалар.

Таһир. Дуслар! Китәмен мин, каласыз сез.
Рәнҗемәгез мине озатканда.
Начарлыкта исемем ят итмәгез,
Су төбендә Таһир ятканда.

Гарәп. Зөһрә җанны инде судан эзләрсең...

Вәзир. Я хода, я! Өнемме бу, төшемме?
Кем син, бу газапларны салучы?
Мең кәһәрләр сарсын үзеңне!

Таһирны суга салалар. (...)

Вәзир тәхеткә ава. Гарәп көлеп суга карый. Гаскәр башлыгы аптырый. Ханча су буена төшеп күзләренә кулын куеп карап тора. Хан ачулы кыяфәт белән урынында кала.

Пәрдә төшә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Җиңү алып кайткан Таһирны ничек каршы алалар?
2. Зинданнан азат ителгәч, Таһир алдында ике юл ачыла: берсе — сөйгәне янына кайту, икенчесе — сугыш кырына китү. Ул кайсын сайлый һәм ни өчен?
3. Хан Таһирга нинди шарт куя? Ул җиңел һәм тиз генә үтәлердәй түгелме?
4. Таһир җырын тагын бер кат укып чыгыгыз. Ни өчен ул, Ханның шартын үтәмичә, Зөһрә исемен атый? Фикер алышыгыз.
5. Ни өчен хан үлем җәзасын башкага — сандыкка салып суга агызуга алмаштыра?

Дүртенче пәрдә

Гөлстан. Бакча. Арткы планда — тирәсендә камышлар үскән Шат суы. (...)

Айсылу, Алка, Акбикә һәм башкалар. (...)

Айсылу *(кинәт).* Тукта, нәрсә килә?

Һәммәсе дә, кулларын күз өсләренә куеп, суга карыйлар.

Әллә нәрсә килә дүрт читле. (...)
Сандык!
Җитә, җитә, кызлар, монда алыйк! (...)

Сандыкны чыгарып уртага, чәчәкләр арасына куялар.

Айсылу. Менә инде хәзер ачып карыйк! (...)
Бар да. Әйдә ач , ач! (...)

Айсылу ачып җибәрә. Таһир чыга, бөтен кызлар куркышалар. (...)

Таһир *(кызларның качканын күргәч, акрын гына күтәрелеп).*

Качмагыз!
Ярдәм миңа... Тизрәк... Ярдәм кирәк...
Сезгә тимәм... Миннән курыкмагыз! (...)
(Чыгып сандык кырыена утыра.)
Сихерләмәм сезне, чибәр кызлар,
Зарар тимәс миннән, гөлләрем! (...)

Айсылу. Кайдан, егет, болай, инсан булсаң,
Чит җирдәнме, безнең илдәнме?
Әллә диңгез төбе сараеннан —
Су кызлары торган җирдәнме?

Таһир. Мине суга аттылар!

Бар да Ах! (...)

Таһир. (...) Кайда соң мин, кемнәр минем белән?
Кемнәр болар шәфкать кошлары?
Кая килеп чыккан мәзлүм егет,
Кайдан аңа чыккан дуслары?
Сөйләгез сез миңа, сылу кызлар...

Айсылу. Тынычлан син инде, чибәрем,
Дуслар сиңа монда һәммәбез дә,

Рәхимледер төшкән илләрең.
Болар, егет, сарай бакчалары,
Атам минем шул ил солтаны;
Өчәүләп без шушы көчле, данлы
Гөлстанның инде кызлары.

Акбикә. Я син, матур егет, кай илләрдән?

Тәһир. Минем илем моннан югары.
Киләмен мин шулай сандыкларда
Аллабирде ханның җиреннән.

Алка. Сөйлә безгә, сине суга салып
Кемнәр аердылар илеңнән?

Тәһир. (...) Бер эш белән миңа очындылар,
Зинданнарга мине яптылар;
Тоташ җиде ел мин шунда яттым. (...)

Айсылу. Ничек чыктың аннан, чибәр егет?

Тәһир. Шулай... бер көн...
Батыр дуслар килделәр дә...
Яшь гомеремне бүләк иттеләр...
Сугыш сафларына ташладым мин
Яшь гомеремнең исле гөлләрен.
Күптән түгел сарай киңәш итте...
Хөкем итте мине асарга... (...)
Ләкин хөкем алмашынды,
Карар булды суга ташларга. (...)

Алка. Инде кай җирләргә китәрсең син?

Тәһир. Кайтам, ахры, туган илләргә. (...)

Кызлар. Кал, яшь йөрәк, кал, ак беләк, безнең матур илдә кал,
Кил, фәрештәдәй матур кызларга кулың билгә сал,
Ямьле-ямьле, тәмле-тәмле, көн итәргә безгә кал.
(...)

Тәһир. Тик калалмыйм, илдә күңлем җәй көтә,
Тик шул илкәем күңелне рәнҗетә.
Әрнетә тик шул бәгырьне, мин китәм,
Ах, китәм — анда мине Зөһрәм көтә. (...)

Айсылу. Зөһрә! Тукта, егет, кем ул Зөһрә?
Ташла серләреңне, кем син, егет?
Матур егет — Тәһир түгелме?
Солтан кызын сөеп газап чиккән
Вәзир углы идең түгелме?

Тәһир. Әйе.

Бар да. Тәһир?

Тәһир. Мин шул...

Айсылу. Сәлам сиңа! (Баш иләр.)
Төгәлләнде, егет, теләгем,
Тәһир-Зөһрәләрне бер күрергә
Ашкынайды күптән йөрәгем.
Тәһир-Зөһрә күптән таныш безгә,
Аларны без күптән ишетәбез.
Сезнең хикәяне сөйли-сөйли
Үтә безнең бик күп кичәбез.
Монда сезне белмәс адәм юктыр.

Алка. Җырларда без сезне җырлыйбыз.

Акбикә. Тәһир-Зөһрә булып уйнашабыз,
Кызганышып кайчак елыйбыз.

Айсылу. Зөһрә матур — нинди бәхетле кыз!

Тәһир. Тукта, телгә алмагыз шул сүзне!
Сагындым мин аны саташырлык,
Авыру басты хәзер күңелне.

Айсылу. Әйдә сарайларга, хәл алырсың,
Зөһрә кызга фаллар ачарбыз;
Аннан күзәтчеләр, атлар биреп,
Ялгыз ярың янга затырбыз... (...)

Пәрдә төшә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Гөлстан илен ничек күз алдына китерәсез?
2. Ни өчен Тәһир бу бәхетле илдә калырга теләми?
3. Тәһир белән Зөһрә турында Гөлстан кызлары нилләр сөйлиләр?
4. Айсылуның «Зөһрә матур — нинди бәхетле кыз!» дигән сүзләрен ничек аңлыйсыз?

Бишенче пәрдә

(...) Сарай эче (...)

Бүлмә бернигадәр буш кала. Бераздан Зөһрә чыга.

Зөһрә. (...) Нинди тавыш?.. Әйе... Онытылганмын,
Бүген туй бәйрәме ләбаса...
Һәммәсен дә адәм күтәрә икән,
Акылыннан язган булмаса... (...)
(Тезләнә)
Кирәк түгел миңа бу таң нуры!
Күзләремнән алыгыз яктысын!

Җитәр инде йөрәк газаплары.
Сүндерегез соңгы чаткысын!
(Кулын күтәргән, ялбарышлы.)

Таһир (кереп). Зөһрәм минем! (...)
Тагын кайттым сиңа, күгәрченем!

Зөһрә. Таһир! Йөрәгем! *(Үксеп ташлана.)* (...)
(...) Синме? Төшем түгелме?
Мин күрдемме тагын үзеңне?
Бу — син! Батыркаем! Тулпарым!
Миһербаным! Газиз дускаем!

Таһир. Асыл кошым минем! Аппагым!

Зөһрә. Балкыр гөлем минем! Яфрагым!
Җәүһәр ташым! Кара күзкәем!
Ефәккәем! Бөдрә чәчкәем!
(Шашынып үбә, иркәли.)

Гарәп *(күзәтеп)*. Тукта, ялгышмыйммы?
Әйе, шул, шул.
Тагын килде сәгать. Нишләргә? (...)
Тукта!... (...)
Татып күрсен инде хәзер
Ачы үлем чишмәсен... *(Югала.)*

Таһир. Зөһрәм! Иркәм! Кулга ал үзеңне!
Китик моннан — сизмәсеннәр безне!

Зөһрә. Әйдә! (...)

Хан, диван, халык, гарәп кераләр. (...)

Хан. Тагын Таһир минем каршымда!
Зиһеннәрем таркау башымда...
Ничә тапкыр аны мин кичердем,
Яраннарның эреп сүзеннән,
Инде һәммәсе дә тик үзеннән —
Артык сорамагыз, бу баланы
Юк итәргә бурычым күземнән.

Зөһрә. Ак теләкләр явар инде
Туган илдән кыйбласына,
Атам минем соңгы чиктә
Шәфкать итсә баласына!
(Хан дәшми.)

Гаскәр башлыгы.
Кичерегез аны бүген дә,
Ялварамын, ханым, мин сезгә. (...)

Таһир. Ялынмагыз, дуслар, ул үзе дә
Әйләнәчәк кара күмергә...

Хан. Җитәр сезгә, җитәр, барыгыз!
Үлем мәйданына илтегез!
Күз алдымнан аны алыгыз!

Таһир. Ярый, алыгыз да шатланыгыз,
Менә башым сезгә — чабыгыз.
Таянмагыз ләкин көчегезгә,
Ул көчегез бары бер көнгә,
Сезгә дә бар урын кара җирдә,
Җир күтәрмәк, белегез, гомергә.
Балаларның аккан каннарыннан
Рәхмәт яумас алтын тәхеткә!
Бер чик булыр золым дөньясына,
Халык кына күрше бәхеткә. (...)

Хан. Алыгыз аны — мәйданга илтегез!

Таһир. Зөһрәм минем!

Зөһрә. Таһирым! (...)

Таһир. Сау бул инде, асыл ярым минем!
Түкмә яшең соңгы туемда,
Дар агачы түгел, син уемда,
Җан газизең минем куйнымда. (...)
(Алып китәләр.) (...)

Зөһрә *(атасына)*.
Никадәрле исемең бөек күрсәм,
Түбән күрдем шулай җаныңны.
Нигә кирәк булды эчү сиңа
Тамчы-тамчы минем каныммы? (...)
(Атасының алдына егыла.)

Пәрдә төшә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Зөһрәнең хис-кичерешләрен күрсәткән юлларны укып күрсәтегез. Ул Таһирны ничек каршы ала?
2. «...Ул үзе дә әйләнәчәк кара күмергә» сүзләре белән Таһир нәрсә әйтергә тели?
3. Таһир Ханга һәм аның якыннарына әйткән сүзләрне укып фикер алышыгыз.
4. Таһирны үлемгә алып киткәч, Зөһрә атасына ниләр әйтә?

ЭПИЛОГ

Беренче күренеш

Биек таш коймалар белән әйләндереп алынган җәза урыны. (...) Бик озак барабан кагыла. (...) Бераздан капка ачыла, озын балтасын тотып кызыл киемнән җәллад керә, аның артыннан ике сакчы Таһирны кертә. Арттан гарәп керә. (...)

Таһир. Хушыгыз сез, бергә кылыч кайрап,
Дау күтәргән якын дусларым!
Бәхилләгез, матурлыклар сайлап
Буй үстергән гүзәл кызларым! *(Дарга менә.)*
Җиткерегез минем хушлавымны
Мәрхүм булган атам рухына,
Онытмагыз аның газапларын,
Хөрмәт сакласагыз улына!
Тапшырыгыз, гидай исәр җилләр,
Сәламемне Зөһрәм, кыйблама —
Хан хөкеменә түгел, башкаемны
Мәхәббәттән иям мин аңа.

Барабан тавышы, карацгылана.

Пәрдә төшә.

Икенче күренеш

Пәрдә күтәрелгәндә гәүдә сузылган, җәллад бер кулына Таһирның башын тотып, бер кулы белән аның тәненә балта каннарын сөртә, шул вакыт яланбаш, яланаяк, юләрләнгән кыяфәт белән Зөһрә килеп чыга. Аннан соң Таһирга сарыла, елый.

Зөһрә. Таһир! Бәгърем! Үлгән... Син... Син, җәллад,
Ник үтердең аны, нишләдең?
Таһир! Салкын инде каннарың да;
Мин нишләрмен хәзер дөньясында? (...)
(Күтәрелеп.)
Җәллад! Җәллад! Азрак кызган мине!
Ал җанымны — миңа ярдәм ит!
Әйдә Таһир янда чыксын җаным,
Көл ит, сөякләрем тар-мар ит!
(Саташа.)
Тукта-тукта... Йөрәк әллә нишли?..
Тукта, җәллад, чапма, рәнҗетмә! (...)
(Акрын.) Таһир, кил, кил, монда, курыкма, кил, кил!

Көтә сине Зөһрә ялгызы... *(Күтәрелеп.)*
Ах, ах, җәллад, ташла Таһир башын! *(Егыла, үлә.)*

Җәллад. Кем бар? Ярдәм! Үлә хан кызы...

Карт йөгереп килә. Шул вакыт гарәп керә дә Зөһрәгә сарыла.

Гарәп. Тукта, нәрсә күрәм, Зөһрә үлә...
(Зөһрәнең алдына таянып.)
Бәгърем, син нишләдең, ай нишләдең?
Бирче җавап — нигә дәшмисең? (...)
Таудай җинаятькә мине илткән
Ал йөзләрең нигә елмаймый? (...)
(Өметсез.)
Салкын!.. Күкрәк суык, бар да бетте...
Тик гәүдәләр калды, рәнҗемә!
Син рәнҗемә, җәллад, мин дә, мин дә...
Зөһрәм җанга киттем мәңгегә...

Хәнҗәре белән үзен үзе чәнчә. (...) Картлар, сакчылар, кешеләр йөгереп керәләр. Тавышлар.

Таһир үлгән! Зөһрә үлгән!
Балакайлар, иң газизләр һәлак ителгән.

Сугышчы алга чыга.

Сугышчы.
(...) Еллар үтәр... Йортлар, илләр, күчәр...
Тугайларны кискән сулар күчәр,—
Онытылыр безнең исемнәр...
Онытылмый мәңге сөйләнерләр
Таһир белән Зөһрә — мескеннәр...

Елаш, музыка, барабан.

Пәрдә төшә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Таһир үзенең соңгы саубуллашу сүзләрен кемнәргә атап әйтә?
2. Зөһрәнең үлеме нәрсәне аңлата?
3. Халык арасында ишетелгән «Балакайлар, иң газизләр һәлак ителгән» дигән сүзләр белән автор нәрсә әйтергә тели?

«Таһир-Зөһрә» трагедиясенә анализ

«Таһир-Зөһрә» трагик сәхнә әсәренең классик схемаларына туры китереп, жанрның бөтен үзенчәлекләрен үз эченә алып эшләнгән. Бу яктан караганда, ул татар драматургиясендә бе-

ренче трагедия дип саналырга хаклы. Әсәрнең **экспозициясендә** без төп геройларның үзара мөнәсәбәтләрен, Зөһрәне яшерен яратучы гарәпнең арага керүен, мәкерлеген күрәбез. Тиздән ханга һәм ханчага яшьләрнең үзара яратышулары мәгълүм була һәм булачак фаҗига чишеп булмастай **төенләнеш** тудыра: бер якта, шәхес иреген, саф мәхәббәтне яклаучы, гомергә бергә булырга теләгән Таһир белән Зөһрә, икенче якта, власть яратучы, үзсүзле, деспот, тигезлек, ирек төшенчәләрен теләсә ничек таптап үтүче хан белән аның якыннары. **Хәрәкәт үстерелеше** буларак, алдагы вакыйга-күренешләрдә геройларның характерлары тагы да киңрәк ачыла, мәхәббәт темасы патриотизм хисе белән үрелеп китә. Гөлстан дәүләтен сурәтләү аша Аллабирде хан җирендәге тигезсезлек, гаделсезлек күрсәтелә. Әсәрдәге каршылык үзенең **кульминацион ноктасына** Таһирның Зөһрәне туй вакытында урлап китәргә омтылган күренештә җитә. Хан белән Таһирның бәрелеше фаҗигале **чишелеш** белән тәмамлана: Таһирның башын кисәләр, моны күтәрә алмыйча Зөһрәнең йөрәге тибүдән туктый, яшерен ярату хисе белән йөргән Гарәп үзен-үзе чәнчеп үтерә.

Әсәр трагедия жанрында язылган. Уңай идеаллар белән яшәүне Таһир мәхәббәте хакына хан власте белән үтеп чыга алмаслык каршылыкка керә һәм һәлак була. Аның үлеме укучы-тамашачыга шәхес иреге, саф мәхәббәт, тигезлек, дөреслек төшенчәләренең өстенлеген, мәңгелек булуын раслый кебек.

Трагедиядә реализм һәм романтизм элементлары кушылып киткән. Бу, бердән, борынгыдан килгән мотивларның дәвам иттерелүе белән аңлатылса, икенчедән, әдип яшәгән чор үзенчәлекләре тәэсиреннән килә. Әсәр 1917—1918 еллар аралыгында, илдә социаль, милли, сыйнфый тигезлек өчен көрәш көчәеп, Февраль һәм Октябрь революцияләре якынлашкан чорда языла. Драматург үзенең уй-фикерләрен, хыялларын романтик образлар, күренешләр аша җиңелрәк җиткерә алган.

«Таһир-Зөһрә»дә шәхеснең саф мәхәббәткә, бәхеткә хокукы барлыгын раслау төп тема итеп алына. Әсәр хан кызы Зөһрәнең Таһирны яратуы, ә вәзир улының битарафлыгы турындагы хәбәр белән башлана. Ул егеткә хат язып беренче булып мәхәббәтен белдерә. Моның белән автор, бер яктан, Зөһрәнең социаль хәлен сиздерсә (хан кызына бөтен нәрсә ярый), икенче яктан, ирләр белән хатын-кыз тигезлеге мәсьәләсен шактый кыю куя. Зөһрә әсәр башында ук нык рухлы, үз сүзендә тора торган, мәхәббәте хакына теләсә нинди адымны ясарга, сарай рәхәтлекләреннән ваз кичәргә әзер булуын күрсәтә. Таһир исә үзен, түбән катлау кешесе буларак, Зөһрәгә тиң түгел дип саный, өметсезлеккә бирелеп мәхәббәтеннән баш тартырга да уйлый.

Ләкин Зөһрәнең ныклыгы, кыюлыгы Таһирга көч бирә, ул мәхәббәте өчен тигезсез көрәшкә ташлана. Таһир әсәрдә мәхәббәт хисендә янучы, аның өчен утны-суны кичәргә әзер егет һәм туган ил азатлыгы өчен күп батырлыклар күрсәткән сугышчы буларак сурәтләнә. Шуның белән бергә ул патриотик тойгыларын, кызны яратуга караганда, өстенрәк куя һәм моның белән туган ил азатлыгының беренчел дәрәҗәдә кыйммәт булуын күрсәтә. Мисал өчен, төрмәдән азат ителгәч, ул сөйгәне янына түгел, ә дошманнарга каршы көрәшкә ашыга.

Мәхәббәтендә дә ул искиткеч ныклык күрсәтә. Хан Зөһрә исемен телгә алмаска шарт куеп шигырь әйтергә кушкач, Таһир, үлем куркынычы янауга карамастан, шәхес иреген, мәхәббәтнең олылыгын раслый:

Тик күңелне кол итә алмаслар
аңардан башкалар.
Ташламам мин Зөһрә исемен,
мәңгегә ятлар күңел.

Күптөрле вакыйга һәм күренешләрдә Таһир дөреслек-тигезлекне, азатлык-хөрлекне яклаучы булып алга килеп баса. Әсәр ахырында ул явызлыкның кайдан, кемнән килгәнен тулысынча аңлаган хәлдә хан турында «...ул үзе дә әйләнәчәк кара күмергә...» ди.

Зөһрәнең сөйгәне Таһир гәүдәсе янында җан бирүе саф мәхәббәтнең бөеклегенә һәм үлемсеалегенә дан җырлау булып яңгырый.

Яшьләр бәхетенә, алар алып килгән уңай идеалларга каршы төшүче кара көч итеп хан власте сурәтләнә. Беренче карашка фаҗига Зөһрәне яшертен яратучы, шуның өчен астыртын һәм мәкерле эш йөртүче Гарәпкә бәйле кебек күренә. Ләкин ул яшьләрнең үлемен тизләтүче бер сәбәп кенә. Ахыр чиктә Таһир белән Зөһрә хан власте, аның тәртипләре корган таш стенага бәрелеп юкка чыгалар.

Дөрес, монда Ханча белән Гарәпнең тәэсире дә шактый була. Яшьләрне аерырга теләп, хан күптән биргән вәгъдәсен бозучы буларак та күрсәтелә. Аллабирде хан дәүләте шәхесне түбәнсетүгә, түбән катлау халыкны изүгә нигезләнгән. Шулыктан моңа капма-каршы буларак Гөлстан сурәтләнә. Авторның идеалында тудырылган бу дәүләттә кешене чыгышыннан түгел, эшеннән чыгып бәяләләр. Гөлстанның солтаны кайчандыр көтү көткән. Бу илдә барлык кешеләр дә тигез, бәхетле яшиләр. Гади халыкның Таһир һәм Зөһрәне яратуы, зурлавы, аерым репликаларда яшәп килгән тәртипләрдән ризасызлык белдерүе, хан властеның мондый хәлдә озак яши алмавын күрсәтә. Ә бу инде Таһир-Зөһрә карашларының җиңүе дигән сүз.

Шулай итеп, Ф. Бурнаш трагедиядә һәртөр явызлыкка кискен каршы чыгып, кеше шәхесенең олылыгын, мәхәббәткә, бәхеткә, тигезлеккә хокукы барлыгын, гуманистик карашларның көчен, җиңеп чыгачагын раслады.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Таһир-Зөһрә» трагедиясенең язылу тарихы турында сөйләгез.
2. Әсәрнең жанр үзенчәлекләрен күрсәтегез.
3. Трагедиянең төп темасын һәм идеясен билгеләгез.
4. Таһир һәм Зөһрә образларына характеристика бирегез.
5. Гөлстан дәүләтенә бәйле күренешләрне автор нигә керткән?
6. Туган илне ярату һәм сөйгән кешегә булган хисләрнең үзара бәйләнеше, бергәлеге турында фикер алышыгыз.
7. Түбәндәге темага язма эш башкарыгыз:
   «Онытылмый мәңге сөйләнерләр
   Таһир белән Зөһрә — мескеннәр...»
8. Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәт тарихын Йосыф-Зөләйха, Хәлил-Галия-бану кебек мәхәббәт геройлары белән чагыштырыгыз.

Трагедия жанры турында

Трагедия жанрының нигезендә көрәшүче якларның килешмәүчән конфликты ята һәм ул, гадәттә, бөек гуманистик идеаллар белән яшәүче трагик геройның үлеме белән тамамлана. Җәмгыятьтәге гаделсезлекләргә, катып калган карашларга каршы көрәштә, көчле рухи тетрәнүләргә, газаплануларга карамастан, трагик герой көчсез булып кала. Үзләренең көчсез, үлем алдында торуларын белә торып, социаль һәм милли тигезлек өчен, азатлык һәм дөреслек өчен, Ватан азатлыгы һәм шәхси мәхәббәте өчен көрәшкәнгә, бу жанр геройлары трагик характерда биреләләр. Трагедияләрдә геройларның үлеме алар максат итеп куйган теләк-омтылыш, идеалларның юка чыгуына китерми, киресенчә, укучы-тамашачы аларның киләчәктә тормышка ашачагына ышана, рухи чистару, үсү тойгылары кичерә.

Агач аяклы дәрвиш *(керә, калтыранган тавыш берлә)*. Сугыш бетте, мин тагы шәһидлектән мәхрүм булдым. Инде нишлим?

Олуг Мөхәммәд. Сине игълан хикмәтулла өчен чувашчирмеш илләренә дин башы иттек. Син үлмәячәксең, үлтермәячәксең, яңыдан-яңы мөселманнар тудырачаксың!

Ягъкуб. Син олуг князьне Мәскәүгә алып барып тәхеткә чыгарачаксың! Хәзер килешү котлы булсын! *(Урамда музыка дәвам итә.)*

Пәрдә төшә.

сарай хадимнәре — сарай хезмәткәрләре	**ялварыш** — үтенеч
яклашалар — якынлашалар	**ләһ** — поляк
төмән — болгар-татар гаскәрендәге хәрби часть	**мажар** — венгр
саг улсын — сау булсын	**үземезнең ясамыз** — үз тәртипләребез
командан — командир	**касд итү** — теләү
	игълан хикмәтулла — белем тарату

Сораулар һәм биремнәр

1. Пьесада Казан ханлыгы тарихындагы нинди вакыйга тасвирлана?
2. Әсәрне укыганнан соң урыс князе Василийгә нинди характеристика бирер идегез?
3. Болгарларның урыс тарихында нинди роль уйнауларына игътибар ителә?
4. Урыс князе Василий Олуг Мөхәммәдкә нинди үтенеч белән мөрәҗәгать итә?
5. Әсирлеккә төшкән Василийгә һәм аның боярларына мөнәсәбәттә Олуг Мөхәммәднең нинди сыйфатлары ачыклана?

8 класс татар әдәбията
Ерәтхи Бурнаш
„Таһир-Зөһрә"